ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 02.12.2025 1880 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль
районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының
педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү
чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә
акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында

«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү буенча комиссия составын расларга (1 нче кушымта).

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә

күләмдә  акчалата компенсацияләү буенча бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль
районы Башкарма комитетының
2025 елның «___» ______ номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы (алга таба - муниципаль район) территориясендәге Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының (алга таба - муниципаль гомуми белем бирү оешмалары) педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2 Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

педагогик хезмәткәр - югары (урта һөнәри) педагогик белемгә ия булган, Алабуга муниципаль районында эшләүче һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында йөкләнеше кимендә бер ставка күләмендә штат вазифасын башкаручы, аның вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик зат;

торак - күчемсез мөлкәт булган торак урын һәм гражданнарның даими яшәве өчен яраклы (билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә җавап бирүче) һәм педагогик хезмәткәрләрнең ата-аналары һәм балигъ булмаган балаларының милке һәм файдалануында булмаган торак урын;

торакны наемга (арендага) бирү түләвен өлешчә яисә тулысынча компенсацияләү – педагогик хезмәткәргә торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) бирү чыгымнарын каплау буенча акчалата түләү;

мөрәҗәгать итүче - Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмасының Алабуга муниципаль районы территориясендә

торак урынны наемга (арендага) бирү өчен тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләүгә дәгъва кылучы педагогик хезмәткәр;

комиссия - педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага) бирү өчен түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү өчен затларны сайлап алу комиссиясе.

1.3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы шартнамәгә таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмасының педагогик хезмәткәре тарафыннан торак урынны наемга (арендага) бирү өчен фактта түләү күләме әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә теркәлә, исәп-хисап (уртача) бәясенә түләү 30 000 сумнан, шул исәптән физик затлар керемнәренә салым 3 (өч) елдан да артмаска тиеш.

1.4. Педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) алу өчен түләүне тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләүне педагогик хезмәткәрнең хезмәт шартнамәсе төзелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмасы гамәлгә ашыра.

1.5. Торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) алу өчен түләүне тулысынча яисә өлешчә компенсацияләү чираттагы финанс елына бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитлары чикләрендә бирелә.

## 2. Педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага бирү) шартнамәсе буенча торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү шартлары һәм тәртибе

2.1. Торакны арендага алган өчен түләүне тулысынча яисә өлешчә компенсацияләү хокукы түбәндәге педагогик хезмәткәрләргә бирелә:

- Россия Федерациясе гражданнары булган;
- Алабуга муниципаль районы территориясендә торак биналарга милек хокукына ия булмаган яки файдалануда булмаган (социаль наем бирү килешүе буенча, махсуслаштырылган наем бирү килешүе буенча), шул исәптән аның гаилә әгъзалары (ир(хатын), балигъ булмаган балалар);
- муниципаль гомуми белем бирү оешмасында кимендә 1 ставка (атнага 18 сәгать) эшкә урнашкан;
- югары һәм / яки урта һөнәри педагогик белемгә ия булган;

- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган;

- торак урынга торак урынны наемга (арендага) язма шартнамә төзегән.

2.2. Айлык акчалата компенсация алу хокукына дәгъва кылучы хезмәткәр үзенең хезмәт шартнамәсе төзелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе исеменә айлык акчалата компенсация алу хокукын алганнан соң биш ел эчендә шушы оешмада эшләргә йөкләмә алуы турында язма йөкләмә рәсмиләштерә.

Әлеге йөкләмә нигезендә җитәкче комиссия алдында хезмәткәрнең торак урынны наемга (арендага) бирү түләве тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турындагы гаризасын карау турында үтенеч белән мөрәҗәгать итә.

2.3. Җитәкче, үтенечнамә белән, педагогик хезмәткәрләргә торак наемга (арендага) бирүгә түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләүгә затларны сайлап алу комиссиясе секретарена комиссия утырышында карау өчен торак урынны наемга (арендага) алуга түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү педагогик хезмәткәр (алга таба - мөрәҗәгать итүче) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында каралган торак урынны наемга (арендага) алуга түләү  формасы буенча тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турында гариза;

2) прописка битен кертеп паспорт күчермәсе;

3) муниципаль гомуми белем бирү оешмасына эшкә кабул итү турындагы боерык күчермәсе;

4) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Алабуга муниципаль районы территориясендә милектә тораклары булмавы турында күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

5) Алабуга муниципаль районы территориясендәге торак урынны наем шартнамәсе (аренда шартнамәсе) күчермәсе;

6) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (Нигезләмәгә 3 нче кушымта);

7) гариза бирүченең торакны арендага алу килешүе буенча түләүләрен раслаучы документлар;

8) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар,

процентлар түләү буенча бурычлар булмау турында салым органының гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 30 календарь көн кала бирелгән белешмә.

2.4. Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш – бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Алабуга муниципаль районы территориясендә торак урыннары булмау турында өземтә алу - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр кысаларында ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.5. Мөрәҗәгать итүче белән торак урынны наемга алу чыгымнарына тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турында шартнамә төзү турындагы карар яисә мондый шартнамә төзүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүче белән әңгәмә йомгаклары буенча комиссия утырышында 2.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган көннән алып 30 эш көне эчендә кабул ителә. Әлеге Нигезләмәдә каралганча, карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

2.6. Наемга (арендага) бирүгә түләү тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турында мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Нигезләмәнең 2.3. пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

2) түләү алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын ачыклау;

3) Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенилар, штрафлар, процентлар түләү буенча гариза бирүченең үтәлмәгән бурычы булу.

2.7. Торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынчы яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү турындагы шартнамә якларның хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын, шул исәптән муниципаль гомуми белем бирү оешмасы белән мөрәҗәгать итүче арасындагы хезмәт шартнамәсе вакытыннан алда өзелгән очракта торак урынны наемга (арендага) түләүгә тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсация бирүне туктату тәртибен һәм шартларын билгели.

2.8. Торакны наемга (арендага) бирү шартнамәсе гамәлдә булу срогы туктатылганда, педагогик хезмәткәр 5 (биш) көн эчендә бу хакта Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмасының эш бирүчесенә хәбәр итә, ә эш бирүче 3 көн эчендә бу хакта комиссиянең җаваплы секретаренә хәбәр итә.

Шул ук күчемсез мөлкәт объектына торакны наемга (арендага)  бирү шартнамәсе шартлары үзгәргән очракта, педагогик хезмәткәр 3 (өч) көн эчендә комиссиянең җаваплы секретарена торакны наемга (арендага) бирү шартнамәсенең яңа күчермәсен җибәрә. Әлеге очракта тулысынча яки өлешчә компенсацияләү үзгәрешсез түләнә.

2.9. Комиссия мөрәҗәгать итүче тапшырган документларның дөреслеген, алардагы белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә хокуклы.

## 3. Финанслау тәртибе

3.1. Торак урынны наемга (арендага) түләүнең тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү турындагы шартнамәдә каралган чыгымнарны финанслау чыганагы булып Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты тора.

1.4. Педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) бирүгә түләү тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләүне педагогик хезмәткәрнең хезмәт шартнамәсе төзелгән муниципаль гомуми белем бирү оешмасы гамәлгә ашыра.

Түләүгә тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсация бирү турындагы шартнамәдә каралган срокларда һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган торак урынны наемга бирү шартнамәсе буенча түләүне гамәлгә ашыруны раслый торган документлар нигезендә, түләү гаризада күрсәтелгән хезмәт хакына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла (Нигезләмәгә 2 нче кушымта).

3.3. Компенсациянең максималь күләме торак урынна арендага бирү өчен фактта түләүгә тигез күләмдә, әмма аена 30 000 сумнан артмаска тиеш..

3.4. Торак урынны наемга (арендага) алган өчен түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләүгә түләү торак урынны наемга (арендага) алган өчен түләүнең тулы яисә өлешчә акчалата компенсациясен гариза бирүченең торак урынны наемга бирү шартнамәсе буенча түләвен раслый торган документлар нигезендә торак урынны наемга (арендага) алган өчен түләүне тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турында шартнамә төзелгән айдан соң килә торган айның 1 числосыннан башлана.

3.5. Торак урынны наемга (арендага) алуга түләүнең тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсациясен бирү турындагы шартнамәне өзү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән срокта ай саен торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча түләүне раслый торган

документларның булмау;

муниципаль гомуми белем бирү оешмасы белән мөрәҗәгать итүче арасындагы хезмәт шартнамәсен өзү;

мөрәҗәгать итүченең һәм/яки аның гаилә әгъзаларының (ир белән хатынның, балигъ булмаган балаларның) торак урыннар сатып алуы (алуы), шулай ук социаль наем шартларында яисә Алабуга муниципаль районы территориясендә махсуслаштырылган урынны наем шартнамәсе буенча урыннар бирү, бу хакта мөрәҗәгать итүче комиссиягә 5 көн эчендә хәбәр итә.

3.6. Бирелә торган белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланган очракта, түләү аны яңарту хокукыннан башка туктатыла.

Нигезсез алынган акчалар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына кайтарыла.

Ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, күрсәтелгән акчалар суд тәртибендә кайтарыла.

3.7. 2.2 пункт шартларын бозган очракта, хезмәт шартнамәсе нигезләмәләре һәм 5 ел вакыт узганчы өзүләр, торак урынны наемга алу чыгымнарын тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү исәбенә түләнгән акчалар мөрәҗәгать итүче тарафыннан район бюджетына кайтарыла.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Торак урынны наем (арендалау) шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) алуга түләүнең тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү турында _____ _ номерлы шартнамә**

Алабуга шәһәре «___»___20 _ ел

Муниципаль гомуми белем бирү оешмасы ____________________ исеменнән ______________________

Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба «Эш бирүче» дип аталачак, бер яктан, Россия Федерациясе гражданины ________________ , алга таба «хезмәткәр» дип аталучы, икенче яктан, бергә «яклар» дип аталучы, _______ 20__педагогик хезмәткәрләргә торак наем (аренда) өчен түләүнең тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләүгә затларны сайлап алу комиссиясе (алга таба - беркетмә), ___ _____ 20__елгы ___ номерлы хезмәт килешүе (алга таба - Хезмәт шартнамәсе) һәм торак урынны наемга (арендага) алу «___» ____ 20__ _ _ _ елда_____ номерлы шартнамәсе (алга таба - торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе) түбәндәгеләр хакында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Әлеге шартнамә буенча эш бирүче комиссиянең уңай нәтиҗәсе һәм торак бинасын арендага алу шартнамәсе буенча түләүне раслаучы документлар нигезендә хезмәткәргә (ай саен) исәп-хисап счетына хисап соңгы айның 25-нче числосыннан соңга калмыйча, торак урынны арендага алу өчен түләүнең тулысынча яки өлешчә акчалата күләмдә компенсациясен күчерә, ләкин торак урынны арендага алу өчен фактик түләү күләменнән исәп-хисап (уртача) бәясенә түләү 30 000 сумнан, шул исәптән физик затлар керемнәренә салым 3 (өч) елдан да артмаска тиеш.

1.2. 1.1 пункты буенча торак урынны наемга (арендага) түләү. әлеге


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Шартнамә чираттагы финанс елына бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән лимитлары чикләрендә башкарыла.

## 2. Эш бирүченең хокуклары һәм бурычлары

2.1. Эш бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

2.1.1. Аена кимендә бер тапкыр, хезмәткәрнең торак урында яшәү фактын акт төзеп, торак урынны наемга (арендага) алу шартнамәсе нигезендә тикшереп торырга.

2.1.2. Хезмәткәр торакны наем (арендалау) шартнамәсе өзгән очракта, шулай ук педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага) алу шартнамәсе буенча торакны наемга (арендага) алуга түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсациясен түләүне туктатырга.

2.2. Эш бирүче түбәндәгеләргә бурычлы:

2.2.1. Хезмәткәргә ай саен, хисаптан соң килүче айның 25 числосыннан да соңга калмыйча, әлеге шартнамәнең 1.1., 1.2. пунктлары нигезендә торак урынны наемга алган өчен түләүнең тулы яисә өлешчә акчалата компенсация суммасын күчерергә.

2.2.2. Торак урынны арендага алган өчен тулы яисә өлешчә акчалата компенсацияне каплау суммасыннан 13% күләмендә физик затлар керемнәренә салым тотып калырга.

## 3. Хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1.1. Эш бирүчедән әлеге шартнамә буенча торак урынны наем (арендалау) өчен түләүнең тулы яисә өлешчә акчалата компенсациясе турында мәгълүмат соратып алырга.

2. Хезмәткәр түбәндәгеләргә бурычлы:

3.2.1. Эш бирүчегә хезмәткәрнең торак урынын наемга алу шартнамәсе шартларының үзгәрүе (өзелүе) турында биш көн эчендә хәбәр итәргә.

3.2.2. Эш бирүчегә, раслаучы документлар белән хезмәткәр яисә аның гаилә әгъзаларының торак урыннарын милеккә алуы турында биш көн эчендә хәбәр итәргә.

3.2.3. Эш бирүчегә Алабуга муниципаль районы территориясендә хезмәткәр яисә аның гаилә әгъзаларының социаль наемга алу шартларын раслаучы документлар белән биш көн эчендә хәбәр итәргә.

3.2.4. Һәр айның 10 числосыннан да соңга калмыйча эш бирүчегә

узган ай өчен торак урынны наемга (арендага) алу шартнамәсе буенча түләүне гамәлгә ашыруны раслый торган документларны тапшырырга;

3.2.5. Нигезсез алынган компенсация суммасының бөтен чорында торакны наем (арендага) шартнамәсе өзелү (туктатылу) факты яшерелгән очракта, торак урынны наемга (арендага) алган өчен түләүнең тулы яисә өлешчә акчалата компенсация суммасын эш бирүчегә түләргә.

## 4. Шартнамәне үзгәртү һәм өзү нигезләре

4.1. Әлеге шартнамә төзелгән шартлар яклар килешүе буенча йә Россия Федерациясе законнары нигезендә үзгәртелергә мөмкин.

4.2. Әлеге шартнамә түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

4.2.1. Якларның килешүе буенча йә әлеге шартнамәдә яисә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда берьяклы тәртиптә.

4.2.2. Хезмәткәр тарафыннан эш бирүчегә торак урынны наемга (арендага) алу шартнамәсе буенча билгеләнгән срокларда түләүне раслаучы документларны тапшырылмау.

4.2.3. Хезмәт шартнамәсен өзү.

4.2.4. Алабуга муниципаль районы территориясендә хезмәткәрнең яисә аның гаилә әгъзаларының милеккә торак урыннары алуы.

4.2.5. Хезмәткәргә яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль наемга алу шартларында торак бирү;

4.2.6. Педагогик хезмәткәрне, торак урынны наемга (арендага) бирүгә акчалата компенсацияләү хокукы бирми торган белгечлеге алмашынып, башка вазифага күчү.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, алар Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылыкка тартыла.

5.2. Форс-мажор хәлләре булганда яклар Россия Федерациясе законнарына таянып эш итәләр.

5.3. Әлеге шартнамә шартлары буенча хезмәткәргә нигезсез алынган компенсациянең бөтен чоры өчен, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган неустойканы капларга, хезмәткәр әлеге шартнамә шартларын үтәмәсә, җитди сәбәпләрсез эштән азат ителсә, бирелә торган

белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланса, торакны наемга (арендага) алу шартнамәсен өзү факты, шулай ук аның ялган булуы ачыкланмаса, хезмәткәр 30 көн эчендә Алабуга муниципаль районы бюджетына акчалар кайтарырга тиеш.

5.4. Эшче тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөрес булмавы ачыкланган очракта түләү туктатыла.

Хезмәткәр алган акчалар әлеге шартнамәнең 5.4 пунктында күрсәтелгән фактлар ачыкланганнан соң 30 көн эчендә Алабуга муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 6. Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты

6.1. Әлеге килешү ________20___ел дәвамында һәм килешү буенча йөкләмәләрне тулысынча үтәгәнче гамәлдә.

6.2. Әлеге шартнамәнең гамәлдә булуы хезмәткәр белән эш бирүче арасында хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылган очракта туктатыла.

## 7. Килешүнең аерым шартлары

7.1. Бәхәсләр һәм каршылыклар килеп чыкканда, яклар аларны сөйләшүләр юлы белән хәл итү өчен бөтен көчен куярга йөкләмә ала.

7.2. Әгәр яклар килешүгә ирешмәгән булса, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

7.3. Әлеге шартнамә белән җайга салынмаган барлык мәсьәләләр буенча яклар Россия Федерациясе законнарына таянып эш итә.

7.4. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә, һәр Як өчен берәр нөсхәдә төзелгән.

## 8. Якларның адреслары, реквизитлары һәм имзалары:

| Эш бирүче | Эшче |
|---|---|
| ________________________ | ______________________ |
| ________________________ | ______________________ |
| ________________________ | ______________________ |

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Җитәкче___________________________

___________________________________
(учреждение атамасы)

_______________________________________

_______________ (кемнән)
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Яшәү (теркәлү) урыны адресы

_______________________________________

Телефон номеры : _____________________

**Гариза**

Торак бинасын наемга (аренда) алу шартнамәсе буенча миңа тулысынча яки өлешчә акчалата компенсация түләүне үтенәм.

Торак бинасын арендага алу (аренда) өчен тулысынча яки өлешчә акчалата күләмдә компенсацияләүне түбәндәге реквизитлар буенча ай саен күчерүне үтенәм _______.

Түбәндәгеләрне белдерәм:

а) милек хокукында яисә файдалану хокукында (социаль наемга алу шартнамәсе яисә махсуслаштырылган урынны наемга алу шартнамәсе буенча) минем һәм гаилә әгъзаларымның торак урыннары юк.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында милеккә яисә файдалануга (социаль наемга алу шартнамәсе яисә махсуслаштырылган Торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча) мин һәм/яки минем гаилә әгъзалары тарафыннан милек хокукында яисә файдалануда торак урын сатып алганда, биш көн эчендә бу хакта эш бирүчегә хәбәр итәргә сүз бирәм.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

1) пропискалы паспорт күчермәсе - 1 нөсхәдә;

2) муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенә эшкә кабул итү турындагы боерык күчермәсен (муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе тарафыннан таныкланган) - 1 нөсхәдә;

3) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Алабуга муниципаль районы территориясендә социаль наемга алу һәм

махсуслаштырылган торак урыннары шартларында торaклары булмавы турында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге белешмәсе - 1 нөсхәдә;

4) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Алабуга муниципаль районы территориясендә милектә торaклары булмавы турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә - 1 нөсхәдә;

5) Алабуга муниципаль районы территориясендәге торак урынны наемга алу шартнамәсе (арендага алу шартнамәсе) күчермәсен, төп нөсхәсе 1 нөсхәдә;

6) шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (Нигезләмәгә 3 нче кушымта) 1 нөсхәдә.;

7) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлар булмау турында салым органының гариза бирелгән көнгә кадәр кимендә 30 календарь көн кала бирелгән белешмә.

20__ елның «____» _________ /_______________/
(Мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 3 нче кушымта

Җитәкче____________________________

___________________________________

(учреждение атамасы)

___________________________________

исеменнән

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Яшәү (теркәлү) урыны адресы

___________________________________

Телефон номеры : ____________________

**Ризалык**

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, шулай ук «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган, автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, торак урынны арендага алган өчен, ә нәкъ менә гамәлләр кылган өчен, минем шәхси мәгълүматларны тулысынча яки өлешчә акчалата компенсацияләү максатларында, минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык күрсәтелгән мәгълүматлар булган тиешле мәгълүматны яки документларны саклауның Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән вакыты чыкканчыга кадәр бирелә.

« ___ » ____________ 20__ел _________

(Мөрәҗәгать итүченең имзасы)

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү тәртибе турындагы турындагы Нигезләмәгә 4 нче кушымта

**Педагогик хезмәткәрләргә яшәү урынын арендага бирүгә акчалата компенсацияләүгә затларны сайлау комиссиясе турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Комиссия муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре тарафыннан торак урынны наемга (арендага) бирү шартнамәсе буенча торак урынны наемга (арендага) бирү түләүне тулысынча яисә өлешчә компенсацияләүгә дәгъва кылучы затларны сайлап алу өчен төзелә (алга таба - комиссия).

1.2. Комиссия составы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана (алга таба - Башкарма комитет).

1.3. Комиссия эшен һәм эш кәгазьләрен җаваплы секретарь оештыра.

1.4. Комиссия 8 кешедән тора.

Комиссия составына Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе керә.

Комиссия рәис, комиссия әгъзалары һәм тавыш бирү хокукы булмаган комиссия секретареннән тора.

1.5. Педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга (арендага) алган өчен түләүнең тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсациясен бүлү өчен комиссия педагогик хезмәткәрләрдән гаризалар кергән саен үткәрелә.

## 5. Комиссия эшен һәм эш башкаруны оештыру

2.1. Комиссия эшен һәм үтәүне оештыру шәхес хокукларын үтәгән һәм шәхси белешмәләрне яклау турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш тәэмин ителә.

2.2. Комиссия эше белән бәйле мәсьәләләр комиссия утырышларына

чыгарыла. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга комиссия рәисе һәм җаваплы секретаре имзалана.

2.3. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 2/3 өлеше катнашкан очракта тулы хокуклы дип санала.

2.4. Торак урынны наем шартнамәсе буенча наемга (арендага) бирүгә түләүне акчалата компенсацияләүгә гариза бирү һәм башка кирәкле документларны махсус журналда теркәү (Педагогик хезмәткәрләргә яшәү урынын наемна (арендага алу) бирүгә акчалата компенсацияләү өчен затларны сайлау комиссиясе турындагы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы).

2.5. Утырыш нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәгеләрне кабул итә:

- муниципаль гомуми белем бирү оешмасына педагогик хезмәткәр белән педагогик хезмәткәрләргә торак урынының билгеләнгән формасы буенча тулысынча яисә өлешчә акчалата компенсацияләү турында шартнамә төзергә киңәш иткән уңай бәяләмә (яшәү урынын арендага алу (аренда) өчен акчалата компенсация бирү турындагы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы);

- сәбәпләре күрсәтелгән, тискәре бәяләмә.

### 3. Комиссия хисаплылыгы

3.1. Комиссия эшен тикшергәндә түбәндәгеләр хисап документлары булып тора:

- комиссия утырышы беркетмәләре;
- документларны теркәү журналы;
- гариза бирүче өчен тәкъдим ителгән документлар пакеты.

Педагогик хезмәткәрләргә торак урынын
наемга (арендага) бирүгә акчалата
компенсацияләүгә затларны сайлау комиссиясе
турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**_____ номерлы педагогик хезмәткәрләргә торак урынны наемга (арендага) бирүгә акчалата компенсация бирү буенча гаризаларны теркәү журналы**

Башлана «___» ______20___елы
Тәмамлана «___» ______20___елы

| № т/б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Һөнәр (вазифа) | Белем бирү оешмалары | Датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның ____ ___ номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә торак урынны наемга бирү чыгымнарын ай саен тулысынча яисә өлешчә күләмдә акчалата компенсацияләү буенча комиссия составы**

| |
|---|
| 1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. Рәис урынбасары:<br>Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары |
| 3. Комиссия секретаре:<br>«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе методисты / белгече |
| Комиссия әгъзалары: |
| 4. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| 5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе (килешү буенча) |
| 6. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 7. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы |
| 8. Алабуга муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы рәисе |

Лист согласования к документу № 1880 от 02.12.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 03.12.2025 16:43

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 03.12.2025 - 20:03 | - |